Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге
Кибәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

10 ноябрь, 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегенең Кибәч торак пунктында 2023 елның 10 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 242 (ике йөз кырык биш).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 134 (йөз утыз дүрт).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 134 (йөз утыз дүрт).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2024 елда Кибәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, көндезге уку формасы студентларын, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- чишмә территориясен чистарту һәм төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов